КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 сентябрь г.Казань № 856

Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкендәге төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын исәпкә алу турында

Россия Федерациясе Дәүләт Советының 2016 елның 17 маендагы утырышы йомгаклары буенча Россия Федерациясе Президентының 2016 елның 11 июнендәге Пр-1138ГС номерлы йөкләмәләре исемлегенең 6 нчы пунктындагы «г» пунктчасын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкендәге төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын исәпкә алу һәм аларның реестрын алып бару буенча нигезләмәне расларга.

2. Төзегәндә Россия Федерациясе бюджет системасының барлык дәрәҗәләрдәге бюджет акчасы кулланылган Татарстан Республикасы территориясендәге төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын исәпкә алуга һәм аларның реестрын алып баруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы итеп Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

аларның балансындагы һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләр һәм предприятиеләр балансындагы төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары күләмнәрен һәм санын этаплап киметү буенча ведомство планнарын раслау;

аларның балансындагы һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләр һәм предприятиеләр балансындагы төзелеп бетмәгән төзелеш объектларына инвентаризация үткәрүне;

төзегәндә Россия Федерациясе бюджет системасының барлык дәрәҗәләрдәге акчасы кулланылган төзелеп бетмәгән төзелеш объектларына мониторинг үткәрүне;

төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары буенча мәгълүматны Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына Нигезләмә белән билгеләнгән тәртип һәм вакытлар нигезендә кертүне.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәэмин итүне тәкъдим итәргә:

аларның балансындагы һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләр һәм предприятиеләр балансындагы төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары күләмнәрен һәм санын этаплап киметү буенча муниципаль планнарны раслауны;

аларның балансындагы һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләр һәм предприятиеләр балансындагы төзелеп бетмәгән муниципаль төзелеш объектларына инвентаризация үткәрүне;

төзегәндә Россия Федерациясе бюджет системасының барлык дәрәҗәләрдәге акчасы кулланылган төзелеп бетмәгән муниципаль төзелеш объектларына мониторинг үткәрүне;

муниципаль милектәге төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары буенча мәгълүматны Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына Нигезләмә белән билгеләнгән тәртип һәм вакытлар нигезендә кертүне.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 20 сентябрь, 856 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасының
дәүләт (муниципаль) милкендәге төзелеп бетмәгән
төзелеш объектларын исәпкә алу һәм аларның реестрын алып бару буенча
нигезләмә

1. Бу Нигезләмә Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкендәге, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук аларның ведомство буйсынуындагы оешмалар балансындагы, Россия Федерациясе бюджет системасының барлык дәрәҗәләрдәге бюджетлар акчасы кулланылган һәм төзелеш кыйммәте 10 млн.сумнан артыграк тәшкил иткән төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын исәпкә алуга һәм аларның реестрын (алга таба – реестр) алып баруга гомуми таләпләрне билгели. Исәпкә алу һәм реестрны алып бару объектларның төзелешен һәм реконструкциясен планлаштырганда бюджет акчасын тотуның нәтиҗәлелеген арттыруга, төзелеп бетмәгән төзелеш күләмен киметүгә юнәлдерелә.

2. Татарстан Республикасы территориясендә төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын исәпкә алу һәм аларның реестрын алып бару Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (алга таба – вәкаләтле орган) йөкләнә.

3. Реестрны алып бару вәкаләтле орган тарафыннан кәгазьдә һәм электрон рәвештә түбәндәге юл белән гамәлгә ашырыла:

төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары турында мәгълүматлар кертү;

реестрдагы төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары турындагы мәгълүматларга үзгәрешләр кертү;

реестрдан төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары турындагы мәгълүматларны төшереп калдыру.

4. Реестрга төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары турында мәгълүматлар кертү, реестрдагы төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары турындагы мәгълүматларга үзгәрешләр кертү, реестрдан төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары турындагы мәгълүматларны төшереп калдыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм җирле үзидарә органнарының бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча төзелеп бетмәгән төзелеш объекты турындагы мәгълүматларны вәкаләтле орган адресына җибәрүе нигез булып тора.

5. Реестр бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча түбәндәге мәгълүматлар чагылдырылып төзелә:

төзелеп бетмәгән төзелеш объектының исеме, аның адресы;

төзелеп бетмәгән төзелеш объектының тибы һәм билгеләнеше;

төзелеп бетмәгән төзелеш объектының хокуклы иясе турында мәгълүматлар;

төзелеп бетмәгән төзелеш объектының егәрлеге;

төзелеп бетмәгән объектның төзелешен фактта туктату көне, ае һәм елы һәм төзелеше алып барылган еллар саны тиешле актлар, бухгалтерлык (финанс) хисаплары документлары яки әлеге мәгълүматларны раслый торган башка документлар нигезендә;

бинаның яки корылманың проект документлары нигезендә проект кыйммәте, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан аларны төзү өчен бүлеп бирелгән акча күләме һәм төзегәндә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бухгалтерлык исәбе документлары яки әлеге кыйммәтләрне раслый торган башка документлар күчермәләре нигезендә үзләштерелгән акча күләме;

төзелеп бетмәгән төзелеш объектын Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә алга таба файдалану турында тәкъдимнәр (төзелешне тәмамлау, объектны консервацияләү, объектны хосусыйлаштыру (сату), объектны башка хуҗалык эшчәнлеге субъектларына тапшыру, объектны Татарстан Республикасы милкенә яки муниципаль милеккә тапшыру, объектны концессиягә тапшыру, төшереп калдыру һәм сүтү), аларга кыскача нигезләү.

6. Вәкаләтле орган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан кертелгән төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары турындагы мәгълүматлар нигезендә реестр төзи.

7. Төзелеп бетмәгән төзелеш объектын исәпкә алу аңа реестр номеры биреп алып барыла, аның формалаштыру структурасы һәм кагыйдәләре вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

8. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм җирле үзидарә органнарының бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымта нигезендә төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары турындагы мәгълүматлар реестры формасы буенча төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары турында мәгълүматлар җибәрүе ел саен хисап елыннан соң килүче елның 1 апреленә кадәр гамәлгә ашырыла.

9. Вәкаләтле орган ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан кертелгән мәгълүматларны исәпкә алып, реестрны яңарта.

10. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары турындагы мәгълүматларны кертмәгән яки тиешенчә кертмәгән, шул исәптән бу Нигезләмәнең 8 нче пункты белән күздә тотылган вакытны бозып, йә вәкаләтле органга әлеге объектлар турында дөрес булмаган һәм (яки) тулы булмаган мәгълүматлар керткән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

Татарстан Республикасының дәүләт (муниципаль) милкендәге төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын исәпкә алу һәм алып бару буенча нигезләмәгә кушымта

Форма

Төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары турында мәгълүматлар реестры

| Т/с | Объектның исеме, адресы | Объектның тибы һәм билгеләнеше | Хокук иясе | Объект-ның егәрлеге | Төзелешнең фактта туктатылу көне | Төзелеш алып ба-рылган еллар саны | Бинаның яки корыл-маның проект кыйммәте, мең сум | Россия Фе-дерациясе-бюджет системасы бюджетла-рыннан бүлеп би-релгән акча күләме, мең сум | Төзегәндә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан үзләштерелгән акча күләме, мең сум | Төзелеп бетмәгән төзелеш объектын алга таба файдалану турында тәкъдимнәр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |